КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 28 декабрь г.Казань № 1228

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының район үзәкләреннән 11 километрдан ераграк урнашкан Татарстан Республикасының ерак булган һәм халык аз яши торган авыл пунктларына беренче дәрәҗәдәге кирәкле товарларны илтүгә бәйле булган кулланучылар кооперациясе оешмалары чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 20 ноябрь, 887 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының район үзәкләреннән 11 километрдан ераграк урнашкан Татарстан Республикасының ерак булган һәм халык аз яши торган авыл пунктларына беренче дәрәҗәдәге кирәкле товарларны илтүгә бәйле булган кулланучылар кооперациясе оешмалары чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 20 ноябрь, 887 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 30 июль, 615 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «ерак булган һәм халык аз яши торган авыл пунктларына» сүзләрен «авыл торак пунктларына» сүзләренә алыштырырга;

преамбулада «ерак булган һәм халык аз яши торган авыл пунктларында» сүзләрен «авыл торак пунктларында» сүзләренә алыштырырга;

1 нче пунктта «ерак булган һәм халык аз яши торган авыл пунктларына» сүзләрен «авыл торак пунктларына» сүзләренә алыштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының район үзәкләреннән 11 километрдан ераграк урнашкан Татарстан Республикасының ерак булган һәм халык аз яши торган авыл пунктларына беренче дәрәҗәдәге кирәкле товарларны илтүгә бәйле булган кулланучылар кооперациясе оешмалары чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибендә:

исемендә «ерак булган һәм халык аз яши торган авыл пунктларына» сүзләрен «авыл торак пунктларына» сүзләренә алыштырырга;

1 нче пунктта «ерак булган һәм халык аз яши торган авыл пунктларына» сүзләрен «авыл торак пунктларына» сүзләренә алыштырырга;

2 нче пунктта «ерак булган һәм халык аз яши торган авыл пунктларына» сүзләрен «авыл торак пунктларына» сүзләренә алыштырырга;

4 нче пунктта «ерак булган һәм халык аз яши торган авыл пунктларына» сүзләрен «авыл торак пунктларына» сүзләренә алыштырырга;

5 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Башка бюджетара трансфертларны алучыларга башка бюджетара трансфертларны бүлү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты белән раслана.

Татарстан Республикасының муниципаль берәмлеге бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертлар күләме (С) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$С = \frac{Р \times Н \times (100 + К_1) \times Ц}{100},$$

монда:

Р – Татарстан Республикасының район үзәкләреннән 11 километрдан ераграк урнашкан Татарстан Республикасының авыл торак пунктларына беренче дәрәҗәдәге кирәкле товарларны илтү өчен файдаланылган транспорт чараларының планлаштырыла торган илтүләр саныннан чыгып исәпләнә торган һәм көтелә торган йөрү юлы, километр;

Н – Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының «Автомобиль транспортында ягулыклар һәм майлау материаллары чыгымы нормалары» методик тәкъдимнамәләрен гамәлгә кертү турында» 2008 елның 14 мартындагы АМ-23-р номерлы боерыгы нигезендә ягулык чыгымының база нормасы, 100 километрга литр;

$К_1$ – Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының «Автомобиль транспортында ягулыклар һәм майлау материаллары чыгымы нормалары» методик тәкъдимнамәләрен гамәлгә кертү турында» 2008 елның 14 мартындагы АМ-23-р номерлы боерыгы нигезендә елның кышкы көннәрендә автотранспортны эшләтү өчен ягулык чыгымының база нормасын күтәрү коэффициенты, процент;

Ц – башка бюджетара трансфертларны бүлгән вакытта Татарстан Республикасының муниципаль берәмлегендә ягулык-майлау материалларына базар бәясе, 1 литрга сум.».

6 нчы пунктта «ерак булган һәм халык аз яши торган авыл пунктларына» сүзләрен «авыл торак пунктларына» сүзләренә алыштырырга;

9 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Башка бюджетара трансфертларны бирү Министрлык һәм башка бюджетара трансфертлар алучы арасында башка бюджетара трансфертлар бирү турында төзелгән килешү нигезендә гамәлгә ашырыла, аның формасы Министрлык тарафыннан раслана.

Башка бюджетара трансфертлар бирү турындагы килешүдә түбәндәгеләр карала:

башка бюджетара трансфертлар бирүнең максатлары, шартлары һәм тәртибе;

башка бюджетара трансфертларның күләме;

башка бюджетара трансфертлар алучы тарафыннан башка бюджетара трансфертлар биргәндә билгеләнгән шартларның үтәлешен тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибе;

башка бюджетара трансфертлардан файдалану турындагы хисапның формасы, аны бирү вакытлары һәм тәртибе;

килешү төзелә торган вакыт;

Министрлык һәм дәүләт финанс тикшерүе органнары тарафыннан башка бюджетара трансфертлар алучының башка бюджетара трансфертлар бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвенә тикшерүләр үткәрү хокукы;

якларның җаваплылыгы.»;

10 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Башка бюджетара трансфертлар Министрлык тарафыннан башка бюджетара трансфертлар бирү турындагы карар кабул ителгән көннән 15 эш көне эчендә Министрлык тарафыннан башка бюджетара трансфертлар алучыларга Федераль казначылыкның территориаль органнарында ачылган шәхси счетларга күчерелә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин